ГЛАВА КЕМЕШ-КУЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д.61, с. Кемеш-Куль, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422147

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КӨМЕШ-КҮЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 61 нче йорт, Көмеш-Күл авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422147

тел.(факс): (85563) 2-46-38; e-mail: KemKul.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар — Постановление

**“ 27 ” октября 2020 г.** — **№ 6**

Мамадыш муниципаль районы Кемеш-Күл авыл җирлеге Алгай авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча узган гражданнар жыенында катнашучы затларны теркәү турында

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының « Көмеш-Күл авыл җирлеге " муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында" гы 2019 **елның 14 октябрендәге 2-44 номерлы** Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге Советы карары белән расланган Нигезләмәнең 3.1 пункты нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1. Алгай авылы клубы житәкчесе Галиева Нурфания Ракип кызын Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлегенең Алгай торак пунктында 2020 елның 18 нояберендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар жыенында катнашучы сайлау хокукына ия булган затларны теркәү өчен җаваплы итеп билгеләргә.
2. Гражданнар жыенында катнашучы затларны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә теркәүне тәэмин итәргә.

3 Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Көмеш-Күл авыл җирлеге башлыгы: И.Н.Салахутдинов